| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2019 Казан шәһәре № 10-86/кс

«Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2018 №10-115/кс карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2020-2021 елларга эчә торган суга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе өчен 2019-2021 елларга эчә торган суга тарифлар билгеләү турында» 05.12.2018 №10-115/кс карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2018 № 10-115/кс карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-86/кс карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе өчен эчә торган суга 2019-2021 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 ел | | 2020 ел | | 2021 ел | |
| | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | |
| 1 | «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 31,84 | 32,73 | 32,73 | 33,51 | 33,51 | 34,96 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 05.12.2018 № 10-115/кс карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2019 № 10-86/кс карары редакциясендә)

# Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе өчен эчә торган суга 2019-2021 елларга тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | | | | | | | |
| 1.1 | «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе | 2019 | 23 917,39 | 1 | - | 6,99 | 1,65 |
| | | 2020 | 24 388,57 | 1 | - | 6,99 | 1,65 |
| | | 2021 | 25 038,03 | 1 | - | 6,99 | 1,65 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге